**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Старочелнинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**
Адрес: 422876, РТ, с. Старые Челны, ул. Центральная, дом 20
тел: : 8 (84346) 79-4-53

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Чаллы авыл Җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Адресы: 422876, РТ, Иске Чаллы авылы, Үзәк ур. 20 йорт
факс: 8 (84346) 79-4-53

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Иске Чаллы ав. КАРАР

2025 елның " 30 " июле №23

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыны (урынын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның «22» мартындагы 15 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

РФ Хөкүмәтенең 28.12.2020 елның № 2314 "Җитештерү һәм куллану калдыклары белән тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә эш итү кагыйдәләрен раслау турында" Карарына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге башкарма комитеты

**Карар бирә:**

1. Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Иске Чаллы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыны (урынын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында" 2023 елның «22» мартындагы 15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1.1 пунктын түбәндәге редакциядә тулыландырырга:

"1.1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампалар тупланган урынның урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә."

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Л. Р. Сибагатуллина